**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О наделении органов местного самоуправления в Республике Татарстан полномочиями на государственную регистрацию актов гражданского состояния»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
18 ноября 2022 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 30 декабря 2005 года № 146-ЗРТ «О наделении органов местного самоуправления в Республике Татарстан полномочиями на государственную регистрацию актов гражданского состояния» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2005, № 12 (IV часть); 2007, № 1 (I часть), № 11; 2008, № 10 (I часть); 2010, № 7 (II часть); 2011, № 5; 2013, № 10; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 33 (часть I); 2018, № 44 (часть I); 2019, № 40 (часть I), № 79 (часть I); 2020, № 57 (часть I) следующие изменения:

1) приложение 2 изложить в следующей редакции:

«Приложение 2
к Закону Республики Татарстан
«О наделении органов местного самоуправления
в Республике Татарстан полномочиями
на государственную регистрацию актов
гражданского состояния»

**Методика**
**определения объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного**

**самоуправления полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния**

1. Настоящая Методика предназначена для определения объема субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных районов и городских округов (далее также – муниципальные образования) из бюджета Республики Татарстан для осуществления органами местного самоуправления полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния.

2. Субвенции бюджетам муниципальных районов предоставляются на обеспечение осуществления полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния органами местного самоуправления муниципальных районов, в том числе органами местного самоуправления входящих в их состав городских и сельских поселений, указанных в приложении 1 к настоящему Закону.

3. Общий объем субвенций, предоставляемых бюджетам муниципальных образований для осуществления полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния ($V_{суб}$), определяется по формуле:

$$V_{суб} = \Sigma\, V_{субi}\ ,$$

где:

$V_{субi}$ – объем субвенции, предоставляемой бюджету i-го муниципального образования.

4. Объем субвенции, предоставляемой бюджету i-го муниципального образования ($V_{субi}$), определяется по формуле:

$$V_{субi} = Z_{нi} + Z_{оi} + M_{зi}\ ,$$

где:

$Z_{нi}$ – расходы на оплату труда работников органов местного самоуправления i-го муниципального образования, осуществляющих полномочия на государственную регистрацию актов гражданского состояния, кроме обслуживающего персонала (далее – работники);

$Z_{оi}$ – расходы на оплату труда обслуживающего персонала органов местного самоуправления i-го муниципального образования, обеспечивающего деятельность по осуществлению полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния (далее – обслуживающий персонал);

$M_{зi}$ – прочие расходы на осуществление полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния в i-м муниципальном образовании.

5. Расходы на оплату труда работников в i-м муниципальном образовании ($Z_{нi}$) определяются по формуле:

$$Z_{нi} = S_{н} \times Q_{нi}\ ,$$

где:

$S_{н}$ – расходы на оплату труда одного работника, которые рассчитываются исходя из должностного оклада, установленного для должности ведущего консультанта в центральных аппаратах органов исполнительной власти Республики Татарстан, выплат, учитываемых при формировании фонда оплаты труда

государственных гражданских служащих (с учетом индексации на соответствующий финансовый год), и страховых взносов;

$Q_{нi}$ – нормативная численность работников в i-м муниципальном образовании.

6. Нормативная численность работников в i-м муниципальном образовании ($Q_{нi}$) определяется по формуле:

$$Q_{нi}=\frac{T_{oi}}{T_{норм}} \times K_{расi} ,$$

где:

$T_{oi}$ – общее время, необходимое для совершения всего количества актов гражданского состояния и иных юридически значимых действий в i-м муниципальном образовании, рассчитываемое в соответствии с административным регламентом предоставления государственной услуги по государственной регистрации актов гражданского состояния органами, осуществляющими государственную регистрацию актов гражданского состояния на территории Российской Федерации, по каждому виду действий;

$T_{норм}$ – норматив рабочего времени в году, который составляет 1980 часов (247,5 рабочего дня в году × 8 рабочих часов в день);

$K_{расi}$ – коэффициент расселения в i-м муниципальном образовании.

7. Коэффициент расселения в i-м муниципальном образовании ($K_{расi}$) определяется по формуле:

$$K_{расi}=\frac{И_i+1}{И+1} ,$$

где:

$И_i$ – удельный вес населения, проживающего в населенных пунктах i-го муниципального образования с численностью населения до 500 человек, в общей численности постоянного населения i-го муниципального образования на конец последнего отчетного года по данным территориального органа статистики;

И – удельный вес населения, проживающего в населенных пунктах с численностью населения до 500 человек, в общей численности постоянного населения в среднем по всем муниципальным образованиям Республики Татарстан на конец последнего отчетного года по данным территориального органа статистики.

8. Расходы на оплату труда обслуживающего персонала в i-м муниципальном образовании ($Z_{oi}$) определяются по формуле:

$$Z_{oi} = S_{oi} \times Q_{oi} ,$$

где:

$S_{oi}$ – расходы на оплату труда одного лица обслуживающего персонала в i-м муниципальном образовании, рассчитываемые исходя из минимального размера оплаты труда и страховых взносов;

$Q_{oi}$ – численность обслуживающего персонала в i-м муниципальном образовании, рассчитываемая исходя из средней фактической численности

обслуживающего персонала в нормативной численности работников в i-м муниципальном образовании за три последних года (пересматривается один раз в пять лет).

9. Прочие расходы на осуществление полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния в i-м муниципальном образовании ($М_{зi}$) определяются по формуле:

$$М_{зi} = М_{зкi} \times Т,$$

где:

$М_{зкi}$ – прочие расходы на осуществление полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния в i-м муниципальном образовании без учета поправочного коэффициента, определяемые по формуле:

$$М_{зкi} = (Z_{нi} + Z_{oi}) \times 0{,}2;$$

Т – поправочный коэффициент, который применяется для расчета прочих расходов на осуществление полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния в случае отклонения от общего объема субвенции, предоставляемой бюджету Республики Татарстан из федерального бюджета, определяемый по формуле:

$$Т = \frac{[V_{субФБ} - \sum_{i=1}^{45}(Z_{нi} + Z_{oi})]}{\sum_{i=1}^{45} М_{зкi}},$$

где:

$V_{субФБ}$ – объем субвенции, предоставляемой бюджету Республики Татарстан из федерального бюджета.»;

2) приложение 3 изложить в следующей редакции:

«Приложение 3<br>к Закону Республики Татарстан<br>«О наделении органов местного самоуправления<br>в Республике Татарстан полномочиями<br>на государственную регистрацию актов<br>гражданского состояния»

**Методика**
**расчета органами местного самоуправления муниципальных районов субвенций, предоставляемых бюджетам городских и сельских поселений из бюджетов муниципальных районов Республики Татарстан для осуществления полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния**

1. Настоящая Методика разработана в соответствии с Бюджетным кодексом Российской Федерации и Бюджетным кодексом Республики Татарстан

и предназначена для расчета органами местного самоуправления муниципальных районов субвенций, выделенных для осуществления полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния, предоставляемых бюджетам городских и сельских поселений, указанных в приложении 1 к настоящему Закону, из бюджетов муниципальных районов Республики Татарстан.

2. Объем субвенции на обеспечение осуществления органами местного самоуправления городских и сельских поселений полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния, предоставляемой бюджетам городских или сельских поселений из бюджета муниципального района Республики Татарстан ($V_{пос}$), определяется по формуле:

$$V_{пос} = \sum_{j=1}^{n} V_{посj} ,$$

где:

$V_{посj}$ – объем субвенции, предоставляемой бюджету j-го городского или сельского поселения из бюджета i-го муниципального района Республики Татарстан.

3. Объем субвенции, предоставляемой бюджету j-го городского или сельского поселения из бюджета i-го муниципального района Республики Татарстан ($V_{посj}$), определяется по формуле:

$$V_{посj} = Z_{нj} + Z_{оj} + M_{зj} ,$$

где:

$Z_{нj}$ – расходы на оплату труда работников органов местного самоуправления j-го городского или сельского поселения, осуществляющих полномочия на государственную регистрацию актов гражданского состояния, кроме обслуживающего персонала (далее – работники);

$Z_{оj}$ – расходы на оплату труда обслуживающего персонала органов местного самоуправления j-го городского или сельского поселения, обеспечивающего деятельность по осуществлению полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния (далее – обслуживающий персонал);

$M_{зj}$ – прочие расходы на осуществление полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния в j-м городском или сельском поселении.

4. Расходы на оплату труда работников в j-м городском или сельском поселении ($Z_{нj}$) определяются по формуле:

$$Z_{нj} = S_{нj} \times Q_{нj} ,$$

где:

$S_{нj}$ – расходы на оплату труда одного работника, которые рассчитываются исходя из должностного оклада, установленного для должности ведущего специалиста-эксперта в центральных аппаратах органов исполнительной власти Республики Татарстан, выплат, учитываемых при формировании фонда оплаты труда государственных гражданских служащих (с учетом индексации на соответствующий финансовый год), и страховых взносов;

$Q_{нj}$ – нормативная численность работников в j-м городском или сельском поселении.

5. Нормативная численность работников в j-м городском или сельском поселении ($Q_{нj}$) определяется по формуле:

$$Q_{нj} = \frac{T_{oj}}{T_{норм}} \times K_{pacj} ,$$

где:

$T_{oj}$ – общее время, необходимое для совершения всего количества актов гражданского состояния и иных юридически значимых действий в j-м городском или сельском поселении, рассчитываемое в соответствии с административным регламентом предоставления государственной услуги по государственной регистрации актов гражданского состояния органами, осуществляющими государственную регистрацию актов гражданского состояния на территории Российской Федерации, по каждому виду действий;

$T_{норм}$ – норматив рабочего времени в году, который составляет 1980 часов (247,5 рабочего дня в году × 8 рабочих часов в день);

$K_{pacj}$ – коэффициент расселения в j-м городском или сельском поселении.

6. Коэффициент расселения в j-м городском или сельском поселении ($K_{pacj}$) определяется по формуле:

$$K_{pacj}=\frac{И_j+1}{И+1} ,$$

где:

$И_j$ – удельный вес населения, проживающего в населенных пунктах j-го городского или сельского поселения с численностью населения до 500 человек, в общей численности постоянного населения муниципального образования на конец последнего отчетного года по данным территориального органа статистики;

И – удельный вес населения, проживающего в населенных пунктах с численностью населения до 500 человек, в общей численности постоянного населения в среднем по всем поселениям муниципального образования на конец последнего отчетного года по данным территориального органа статистики.

7. Расходы на оплату труда обслуживающего персонала в j-м городском или сельском поселении ($Z_{oj}$) определяются по формуле:

$$Z_{oj} = S_{oj} \times Q_{oj} ,$$

где:

$S_{oj}$ – расходы на оплату труда одного лица обслуживающего персонала в j-м городском или сельском поселении, рассчитываемые исходя из минимального размера оплаты труда и страховых взносов;

$Q_{oj}$ – численность обслуживающего персонала в j-м городском или сельском поселении, рассчитываемая исходя из средней фактической численности обслуживающего персонала в нормативной численности работников в j-м городском или сельском поселении за три последних года (пересматривается один раз в пять лет).

8. Прочие расходы на осуществление полномочий на государственную регистрацию актов гражданского состояния в j-м городском или сельском поселении ($M_{зj}$) определяются по формуле:

$$M_{зj} = (Z_{нj} + Z_{оj}) \times 0{,}2.»$$.

**Статья 2**

1. Настоящий Закон вступает в силу с 1 января 2023 года.

2. Действие Закона Республики Татарстан от 30 декабря 2005 года № 146-ЗРТ «О наделении органов местного самоуправления в Республике Татарстан полномочиями на государственную регистрацию актов гражданского состояния» (в редакции настоящего Закона) распространяется на правоотношения, возникающие при формировании бюджетов бюджетной системы Республики Татарстан, начиная с бюджетов на 2023 год и на плановый период 2024 и 2025 годов.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
01 декабря 2022 года
№ 88-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 18 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 11; 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5; 2013, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 57 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә
органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә
алу вәкаләтләрен бирү турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

**Җирле үзидарә органнары тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү методикасы**

1. Әлеге Методика җирле үзидарә органнары тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль

районнар һәм шәһәр округлары (алга таба шулай ук – муниципаль берәмлекләр) бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү өчен каралган.

2. Муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары, шул исәптән алар составына керә торган әлеге Законга 1 нче кушымтада күрсәтелгән шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары, тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә бирелә.

3. Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме ($V_{суб}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{суб} = \Sigma\ V_{субi}\ ,$$

монда:

$V_{субi}$ – i-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенция күләме.

4. I-муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган субвенция күләме ($V_{субi}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{субi} = Z_{нi} + Z_{oi} + M_{зi}\ ,$$

монда:

$Z_{нi}$ – i-муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләренә (алга таба – хезмәткәрләр) хезмәт өчен түләү чыгымнары, хезмәт күрсәтү персоналыннан тыш;

$Z_{oi}$ – i-муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеген тәэмин итүче хезмәт күрсәтү персоналына (алга таба – хезмәт күрсәтү персоналы) хезмәт өчен түләү чыгымнары;

$M_{зi}$ – i-муниципаль берәмлегендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга башка чыгымнар.

5. I-муниципаль берәмлегендә хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнары ($Z_{нi}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Z_{нi} = S_{н} \times Q_{нi}\ ,$$

монда:

$S_{н}$ – бер хезмәткәргә хезмәт өчен түләү чыгымнары, алар Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының үзәк аппаратларында әйдәп баручы консультант вазыйфасы өчен билгеләнгән вазыйфаи окладтан, дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда исәпкә алына торган түләүләрдән (тиешле финанс елына индексация ясауны исәпкә алып) һәм иминият кертемнәреннән чыгып санала;

$Q_{нi}$ – i-муниципаль берәмлегендә хезмәткәрләрнең норматив саны.

6. I-муниципаль берәмлегендә хезмәткәрләрнең норматив саны ($Q_{нi}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Q_{нi} = \frac{T_{oi}}{T_{норм}} \times K_{расi},$$

монда:

$T_{oi}$ – i-муниципаль берәмлегендә граждан хәле актларының һәм юридик әһәмияткә ия башка гамәлләрнең барлык күләмен башкару өчен кирәкле гомуми вакыт, ул Россия Федерациясе территориясендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнар тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты нигезендә гамәлләрнең һәр төре буенча санала;

$T_{норм}$ – елда эш вакыты нормативы, ул 1980 сәгать (елда 247,5 эш көне х көненә 8 эш сәгате) тәшкил итә;

$K_{расi}$ – i-муниципаль берәмлегендә халыкны урнаштыру коэффициенты.

7. I-муниципаль берәмлегендә халыкны урнаштыру коэффициенты ($K_{расi}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_{расi} = \frac{И_i + 1}{И + 1},$$

монда:

$И_i$ – халык саны 500 кешегә кадәр булган i-муниципаль берәмлеге торак пунктларында яшәүче халыкның i-муниципаль берәмлегендә территориаль статистика органы мәгълүматлары буенча соңгы хисап елы ахырына даими яшәүче халыкның гомуми санында чагыштырма күләме;

$И$ – халык саны 500 кешегә кадәр булган торак пунктларда яшәүче халыкның Татарстан Республикасы барлык муниципаль берәмлекләрендә территориаль статистика органы мәгълүматлары буенча соңгы хисап елы ахырына даими яшәүче халыкның уртача гомуми санында чагыштырма күләме.

8. I-муниципаль берәмлегендә хезмәт күрсәтү персоналына хезмәт өчен түләү чыгымнары ($Z_{oi}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Z_{oi} = S_{oi} \times Q_{oi},$$

монда:

$S_{oi}$ – i-муниципаль берәмлегендә хезмәт күрсәтү персоналы булган бер затка хезмәт өчен түләү чыгымнары, алар минималь хезмәт хакы күләменнән һәм иминият кертемнәреннән чыгып санала;

$Q_{oi}$ – i-муниципаль берәмлегендә хезмәт күрсәтү персоналының саны, ул соңгы өч елда i-муниципаль берәмлегендә хезмәткәрләрнең норматив санында хезмәт күрсәтү персоналының факттагы уртача саныннан чыгып санала (биш елга бер тапкыр яңадан карала).

9. I-муниципаль берәмлегендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бүтән чыгымнар ($М_{зi}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$М_{зi} = М_{зкi} \times Т ,$$

монда:

$М_{зкi}$ – i-муниципаль берәмлегендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга, төзәтмәләр коэффициентыннан тыш, башка чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$М_{зкi} = (Z_{нi} + Z_{oi}) \times 0,2;$$

Т – төзәтмәләр коэффициенты, ул, Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субвенциянең гомуми күләменнән тайпылган очракта, граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга башка чыгымнарны исәпләү өчен кулланыла һәм түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Т = \frac{[V_{субФБ} - \sum_{i=1}^{45}(Z_{нi} + Z_{oi})]}{\sum_{i=1}^{45} М_{зкi}},$$

монда:

$V_{субФБ}$ – Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субвенция күләме.»;

2) 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә<br>органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә<br>алу вәкаләтләрен бирү турында»<br>Татарстан Республикасы Законына<br>3 нче кушымта

**Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан бирелә торган субвенцияләрне муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпләү методикасы**

1. Әлеге Методика Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бүлеп бирелгән, әлеге

Законга 1 нче кушымтада күрсәтелгән шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы муниципаль районнары бюджетларыннан бирелә торган субвенцияләрне муниципаль районнарның җирле үзидарә органнары тарафыннан исәпләү өчен кулланыла.

2. Шәһәр һәм авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнары тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә шәһәр яисә авыл җирлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган субвенция ($V_{пос}$) күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{пос} = \sum_{j=1}^{n} V_{посj} ,$$

монда:

$V_{посj}$ – j-шәһәр яисә авыл җирлеге бюджетына Татарстан Республикасы і-муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган субвенция күләме.

3. J-шәһәр яисә авыл җирлеге бюджетына Татарстан Республикасы і-муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган субвенция күләме ($V_{посj}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{посj} = Z_{нj} + Z_{oj} + M_{зj} ,$$

монда:

$Z_{нj}$ – j-шәһәр яисә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы хезмәткәрләренә (алга таба – хезмәткәрләр) хезмәт өчен түләү чыгымнары, хезмәт күрсәтү персоналыннан тыш;

$Z_{oj}$ – j-шәһәр яисә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеген тәэмин итүче хезмәт күрсәтү персоналына (алга таба – хезмәт күрсәтү персоналы) хезмәт өчен түләү чыгымнары;

$M_{зj}$ – j-шәһәр яисә авыл җирлегендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга башка чыгымнар.

4. J-шәһәр яисә авыл җирлегендә хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү чыгымнары ($Z_{нj}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Z_{нj} = S_{нj} \times Q_{нj} ,$$

монда:

$S_{нj}$ – бер хезмәткәргә хезмәт өчен түләү чыгымнары, алар Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының үзәк аппаратларында әйдәп баручы белгеч-эксперт вазыйфасы өчен билгеләнгән вазыйфаи окладтан, дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү фондын формалаштырганда исәпкә алына торган түләүләрдән (тиешле финанс елына индексация ясауны исәпкә алып) һәм иминият кертемнәреннән чыгып санала;

$Q_{нj}$ – j-шәһәр яисә авыл җирлегендә хезмәткәрләрнең норматив саны.

5. J-шәһәр яисә авыл җирлегендә хезмәткәрләрнең норматив саны ($Q_{нj}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Q_{нj} = \frac{T_{oj}}{T_{норм}} \times K_{pacj} ,$$

монда:

$T_{oj}$ – j-шәһәр яисә авыл җирлегендә граждан хәле актларының һәм юридик әһәмияткә ия башка гамәлләрнең барлык күләмен башкару өчен кирәкле гомуми вакыт, ул Россия Федерациясе территориясендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнар тарафыннан граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты нигезендә гамәлләрнең һәр төре буенча санала;

$T_{норм}$ – елда эш вакыты нормативы, ул 1980 сәгать (елда 247,5 эш көне x көненә 8 эш сәгате) тәшкил итә;

$K_{pacj}$ – j-шәһәр яисә авыл җирлегендә халыкны урнаштыру коэффициенты.

6. J-шәһәр яисә авыл җирлегендә халыкны урнаштыру коэффициенты ($K_{pacj}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$K_{pacj} = \frac{И_j + 1}{И + 1} ,$$

монда:

$И_j$ – халык саны 500 кешегә кадәр булган j-шәһәр яисә авыл җирлеге торак пунктларында яшәүче халыкның муниципаль берәмлектә территориаль статистика органы мәгълүматлары буенча соңгы хисап елы ахырына даими яшәүче халыкның гомуми санында чагыштырма күләме;

И – халык саны 500 кешегә кадәр булган торак пунктларда яшәүче халыкның муниципаль берәмлекнең барлык җирлекләрендә территориаль статистика органы мәгълүматлары буенча соңгы хисап елы ахырына даими яшәүче халыкның уртача гомуми санында чагыштырма күләме.

7. J-шәһәр яисә авыл җирлегендә хезмәт күрсәтү персоналына хезмәт өчен түләү чыгымнары ($Z_{oj}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Z_{oj} = S_{oj} \times Q_{oj} ,$$

монда:

$S_{oj}$ – j-шәһәр яисә авыл җирлегендә хезмәт күрсәтү персоналы булган бер затка хезмәт өчен түләү чыгымнары, алар минималь хезмәт хакы күләменнән һәм иминият кертемнәреннән чыгып исәпләнә;

$Q_{oj}$ – j-шәһәр яисә авыл җирлегендә хезмәт күрсәтү персоналы саны, ул соңгы өч елда j-шәһәр яисә авыл җирлегендә хезмәткәрләрнең норматив санында хезмәт күрсәтү персоналының факттагы уртача саныннан чыгып санала (биш елга бер тапкыр яңадан карала).

8. J-шәһәр яисә авыл җирлегендә граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бүтән чыгымнар ($M_{зj}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$M_{зj} = (Z_{нj} + Z_{oj}) \times 0{,}2.»$$.

**2 статья**

1. Әлеге Закон 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
2. «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында» 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (әлеге Закон редакциясендә) гамәли көче Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын формалаштырганда барлыкка килүче хокук мөнәсәбәтләренә 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджетлардан башлап кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 01 декабрь
№ 88-ТРЗ